| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.12.2017 Казан ш. № 3-9/э

«Энерготранзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 10.12.2015 № 3-14/э карары белән билгеләнгән дәвамлы хосусый тарифларга 2018 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Ваклап сату (кулланучылар) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифларны һәм бәяләрне хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм «Электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә кирәкле тулай табышны дәвамлы индексацияләү ысулын кулланып билгеләнә торган тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, җайга салынулы оешмаларның зарури тулай табышын исәпкә алып, «Энерготранзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә дәвамлы хосусый тарифларга 2018 ел өчен төзәтмәләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2016-2018 елларга «Энерготранзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә хосусый тарифлар билгеләү турында» 10.12.2015 № 3-14/э карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 08.12.2016 № 3-9/э,

03.02.2017 № 3-1/э карарлары керткән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны шушы карарның 1 нче кушымтасы буенча төзәтелгән яңа эчтәлегендә бәян итәргә;

3 нче кушымтаны шушы карарның 2 нче кушымтасы буенча төзәтелгән яңа эчтәлегендә бәян итәргә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис в.б. А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 08.12.2017 № 3-9/ карарына 1 нче кушымта
«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 10.12.2015 № 3-14/э карарына 1 нче кушымта

«Энерготранзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә 2016 елның 1 гыйнварыннан 2018 елның 31 декабренә кадәр календарь буенча бүленгән хосусый тарифлар

| № п/п | Челтәр оешмасының аталышы | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | технологик сарыф (югалтулар) өчен түләү ставкасы | | электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | технологик сарыф (югалтулар) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1 | «Энерготранзинт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте | 2016 | 458 839,17 | 212,71 | 1,4160 | 458 839,17 | 207,54 | 1,4108 |
| | | 2017 | 622 540,00 | 275,78 | 2,04862 | 622 540,00 | 295,08 | 2,06793 |
| | | 2018 | 803 398,91 | 326,95 | 2,68408 | 803 398,91 | 340,03 | 2,69715» |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 08.12.2017 № 3-9/ карарына 2 нче кушымта
«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 10.12.2015 № 3-14/э карарына 3 нче кушымта

«Энерготранзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең
2016-2018 елларга зарури тулай табышы
(сарыфларга түләүне исәпкә алмыйча)

| № п/п | Татарстан Республикасында челтәр оешмасының аталышы | Ел | Югалтулар өчен түләүне исәпкә алмыйча, челтәр оешмасының ЗТТ |
|---|---|---|---|
| | | | мең сум |
| 1 | «Энерготранзинт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 2016 | 22 756,59 |
| | | 2017 | 36 157,12 |
| | | 2018 | 51 385,39» |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге